| | |
|---|---|
| **ГЛАВА МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.11.2022 г. Кече Мәми авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Кече Мәми авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2022 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 24 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми

авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- Кече Мәми авылында урам утларын ремонтлау;
- территорияне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту
- Кече Мәми авылында материаллар һәм җиһазлар белән ял паркын төзекләндерү;
- Кече Мәми авылы территориясен чабу;

*б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*в) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:*

- зиратны материаллар алу белән чистарту.

« РИЗА»　　　　　　　　«КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы**　　　　**Е.Н. Алексеева**